КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 сентябрь г.Казань № 813

**Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 8 сентябрь, 813 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели, әлеге бүлмәләрнең милекчеләре (алга таба – субсидия алучы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын (алга таба – төбәк программасы) тормышка ашыру кысаларында «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 6 өлешенең 2 пункты нигезендә капиталь ремонт фондларын төзи.

2. Бюджет акчасы белән баш эш итүче булып бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – баш эш итүче) тора.

3. Субсидия баш эш итүче тарафыннан субсидия алучыга бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максат өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында баш эш итүчегә каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидия алу хокукына түбәндәге критерийларга җавап бирә торган субсидия алучы ия:

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән юридик зат булып тора;

күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аның гамәлгә куючысы булган махсуслаштырылган коммерциягә карамаган оешма булып тора.

5. Субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айның 1енә субсидия алучы туры килергә тиешле таләпләр:

салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында башка үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмау.

6. Субсидия алу өчен субсидия алучы баш эш итүчегә түбәндәге документларны тапшыра:

субсидияне алу өчен ирекле формада язылган гариза;

агымдагы елда субсидия хисабына гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча эшләр башкарырга һәм (яки) хезмәтләр күрсәтергә планлаштырыла торган күпфатирлы йортлар исемлеге;

милекчеләрнең капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын билгеләү турындагы карарлары реквизитларын күрсәтеп, күпфатирлы йортлар реестры яисә Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясындагы 7 өлеше нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актлар;

субсидия алучының бу Тәртипнең 4, 5 нче пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүен раслый торган документлар;

субсидия алучының Россия Федерациясе Торак кодексының 180 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Россия кредит оешмасында яки Россия Федерациясе Торак кодексының 180 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган счет (алга таба – субсидия алучының счеты) реквизитлары.

Тапшырыла торган документларның күчермәләре субсидия алучы исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат тарафыннан расланырга тиеш.

7. Субсидия алучы үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язмасы бите күчермәсен;

салым органында исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Субсидия алучы тарафыннан бу пунктта күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, баш эш итүче әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Баш эш итүче заявканы кергән көнендә терки һәм эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә аны карап тикшерә, субсидия бирү йә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Баш эш итүче субсидия алучыга тиешле карар кабул ителгән көннән бер эш көне эчендә кабул ителгән карар турында язмача хәбәр итә.

9. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучының бу Тәртипнең 4 һәм 5 нче пунктлары белән билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 6 нчы пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән заявкадагы һәм документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

10. Субсидия тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасы чараларын тормышка ашыру» һәм «Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» ярдәмче программалары кысаларында күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау чараларын тәэмин итүгә каралган күләмдә бирелә.

11. Субсидия бирү баш эш итүче һәм субсидия алучы арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә төзелә.

12. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

субсидия бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре;

субсидия күчерү тәртибе;

күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яки) эшләр башкару исемлеге;

субсидия алучының һәм килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булган затларның баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан аларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы;

өстәмә хисаплылык бирү вакытлары һәм формасы (кирәк булганда);

алынган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны (югары технологияле чит ил җиһазы, чималы һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) тыю;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешен кире кайтару очраклары һәм тәртибе;

баш эш итүче тарафыннан субсидиянең калган өлешләрен файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләре торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр.

Кирәк булганда килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.

13. Акча белән баш эш итүче килешү төзелгән көннән 10 эш көне эчендә субсидия алучының счетына субсидия күләменең 30 процентына тигез булган аванс күчерә, субсидиянең калган өлеше квартал саен, кварталның беренче аеның 15еннән дә соңга калмыйча, тигез өлешләр белән күчерелә.

14. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып Тиешле елга төбәк программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планына кертелгән күпфатирлы йортларга капиталь ремонтны 100 процент үткәрү тора.

15. Субсидия алучы ел саен, хисап елыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, баш эш итүчегә бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап (хисап елыннан соң килә торган айның 1е хәленә карата) бирә.

16. Баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучыларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә Россия Федерациясе законнары нигезендә тикшерүләр үткәрә.

17. Субсидия баш эш итүченең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар биргәндә һәм документлар тапшырганда;

билгеләнгән вакытта субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап, өстәмә хисаплылык (әгәр дә ул килешүдә билгеләнгән булса) бирмәгәндә;

субсидия биргәндә билгеләнгән, баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары тикшерүләре фактлары буенча ачыкланган шартларны бозганда;

субсидия акчасыннан максатчан файдаланмаганда;

субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешмәгәндә;

18. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш (баш эш итүче тарафыннан әлеге акчаны файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш).

19. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 17 һәм 18 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытлары бозылганда, баш эш итүче субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

20. Субсидияләрдән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту баш эш итүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта

Форма

20__ елның «__» __________ына(енә)

________________________________________________________________________
(коммерциягә карамаган оешманың исеме)
субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап

| Т/с | Нәтиҗәнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Нәтиҗә-нең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Коммерциягә карамаган оешманың
җитәкчесе ____________ ______________ ________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

20__ , «__» ________

______________________________